РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» февраль 2022г. г. Альметьевск №125

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 28 сентябрендәге 79 номерлы «Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Әлмәт шәһәр Советының Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру турындагы тәкъдимен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә кабул итү турындагы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 елеше, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы, Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләр вәкаләтләрнең бер елешен тапшыру (кабул итү) турында 2015 елның 6 маендагы 468 номерлы карары белән расланган килешүләр тезү Тәртибе, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» 2021 елның 28 сентябрендәге 47 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәр Советы карары нигезендә, «Кодекс» мәгълүмат системасының «Региональ законнар Аналитигы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын куллану практикасы» темасы буенча видеоконференция режимын узган киңәшмә беркетмәсенең 3 пунктына таянып,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 28 сентябрендәге 79 номерлы «Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Әлмәт шәһәр Советының Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең

бер елешен гамәлгә ашыру турындагы тәкъдимен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә кабул итү турындагы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 нче, 2 нче кушымтаның 6 пунктындагы 3 абзацында «гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын үткәрү турында һәм аларны уздыруны оештыралар» сүзләрен «гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу яисә килеп чыгу куркынычы булганда эвакуация чараларын оештыралар һәм уздыралар» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1 нче, 2 нче кушымтаның 6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 16 абзац өстәргә:

«-федераль, төбәкара, региональ, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетергәндә Россия Федерациясе гражданнарының, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның гадәттән тыш хәл зонасында булган торак урыннарында яшәү фактларын, аларның тормыш-көнкүреше шартларын бозуны һәм гадәттән тыш хәл аркасында алар тарафыннан мөлкәт югалуны билгеле.»;

1.3. 1 нче, 2 нче кушымтаның 32 пункты 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32. Федераль закон нигезендә, шәһәр ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итү,:".

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә. Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар буенча (А.И. Грушин), икътисадый үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча (Мингазов И. М.) даими комиссияләренә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов